РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«16» март 2021 с. Тюлячи № 102

«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру буенча район комиссиясе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль Программасын гамәлгә ашыру буенча район комиссиясе (алга таба - Комиссия) составын түбәндәге тәртитә расларга:

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Хәмидуллин И.Х. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе. |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары. |

Комиссия сәркатибе:

| | | |
|---|---|---|
| Дәүлиева Р.М. | - | Теләче муниципаль районы МБУ Теләче җирлекара китапханәсе директоры. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Иксанов Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Карпова Н.В. | - | МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгы; |
| Хуҗин Л.Й. | - | «Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләче-информ» мәгълүмат үзәге директоры (килешү буенча); |
| Яруллин Р.Н. | - | Теләче муниципаль район Советының оештыру |

бүлеге башлыгы;

Газизов М.М. - Теләче муниципаль районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча);

Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).

2. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль Программасын гамәлгә ашыру буенча район комиссиясе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«16» 03 2021 № 102
карарына кушымта

**«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль Программасын гамәлгә ашыру буенча район комиссиясе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль Программасын гамәлгә ашыру буенча район комиссиясе (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Теләче муниципаль районы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында (алга таба - телләр өлкәсендә дәүләт сәясәте) даими эшләүче орган булып тора, Теләче муниципаль районы гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Теләче муниципаль районында яшәүче халыкларның башка телләрен файдалануга хокукларын тәэмин итә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, гамәлдәге федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә башкара.

## 2. Бурычлар

2.1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Администрация), иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар арасында телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Теләче муниципаль районы территориясендә яшәүче халыкларның башка телләреннән файдалануга хокукларын тәэмин итү белән бәйле мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлекне тормышка ашыру.

2.2. Телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенә кагылышлы программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруга ярдәм итү, күрсәтелгән программаларның һәм проектларның нәтиҗәлелеген анализлау, кирәк булганда, аларны үзгәртү турында тәкъдимнәр эшләү.

2.3. Теләче муниципаль районында телләр турындагы законнарның үтәлешенә мониторинг үткәрү.

2.4. Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча структур бүлекчәләргә, фәнни оешмаларга, белем бирү оешмаларына методик һәм консультацион ярдәм күрсәтү.

## 3. Функцияләре

3.1. Теләче муниципаль районы территориясендә телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү.

3.2. Утырышларда Теләче муниципаль районында телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру турында җитәкчеләрнең, район администрациясе бүлекләре вәкилләренең, хакимият, иҗтимагый оешмалар вәкилләренең докладларын тыңлау.

3.3. Теләче муниципаль районы территориясендә эшләүче дәүләт һәм муниципаль органнар, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре белән телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү.

3.4. Татарстан Республикасында дәүләт телләрен тигез файдалану өлкәсендә хокук бозуларны бетерү һәм булдырмау максатларында кануннар нигезендә карарлар кабул итү өчен администрация тарафыннан, Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан теләсә нинди формадагы оешмаларга мәгълүмат бирү.

**4. Хокук**

4.1. Администрациядән, иҗтимагый берләшмәләрдән, мәдәният һәм сәнгать оешмаларыннан, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалардан, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган оешмалардан, шулай ук аларның вазыйфаи затларыннан кирәкле материаллар соратырга һәм алырга.

4.2. Кирәк булганда, тиешле тәртиптә Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, хуҗалык итүче субъектларны Комиссия компетенциясенә керүче карарлар һәм башка материаллар әзерләүдә катнашу өчен җәлеп итәргә.

4.3. Үз утырышларына телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, шул исәптән коммерцияле булмаган оешмалар вәкилләренең хисапларын тыңларга һәм үз утырышларына чакырырга.

4.4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан комиссиянең компетенциясенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр буенча уздырыла торган киңәшмәләрдә, семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

**5. Эшне оештыру**

5.1. Комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатип һәм әгъзалары, шулай ук комиссия составына кермәгән мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, аның эшендә катнашучы педагоглар составында формалаша. Комиссия составы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.2. Комиссияне комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итүче рәис җитәкли, комиссия эшчәнлеген тәэмин итүче карарлар кабул итә, комиссия әгъзаларының эшен координацияли, чираттагы утырышта каралырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели, комиссия утырышларын, шул исәптән Теләче муниципаль районы башкарма комитеты, ведомство буйсынуындагы оешмалар һәм башка хакимият органнары, аның әгъзалары булмаган идарә органнары җитәкчеләре һәм вәкилләре катнашында билгели. Комиссия эше нәтиҗәләре буенча үз вәкаләтләре

кысаларында карарлар кабул итә. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, аның вазыйфаларын рәис урынбасары башкара.

5.3. Комиссия сәркатибе:

- утырышлар беркетмәләрен алып бара, комиссия кабул иткән карарларның үтәлеше турында мәгълүмат әзерли, «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы чараларын тормышка ашыруны контрольдә тота, комиссия утырышларына әзерлекне оештыра, төрле ведомстволардан алынган мәгълүматны җыю һәм гомумиләштерүне контрольдә тота, билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимият органнарыннан һәм башка оешмалардан Комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүматны соратып ала;

- Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләр беркетмәләре нигезендә йөкләмәләрне үтәү буенча җаваплы хатларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра һәм проектларын әзерли;

- Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының соратулары һәм хисап формалары нигезендә тиешле айда Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы Татарстан Республикасы законнарының Теләче муниципаль районында үтәлеше турында белешмәләр җыю һәм әзерләүне гамәлгә ашыра.

5.4. Комиссия утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

5.5. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.6. Комиссия карарлары комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.7. Комиссия карарларының үтәлешен район комиссиясе сәркатибе контрольдә тота.

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев